## Иман

# ПАКЪЛЕК

اَلطُّهُورُ شَطْرُ الْإِيمَانِ ، وَ الْحَمْدُ لِلَّهِ تَمْلَأُ الْمِيزَانَ ، وَ سُبْحَانَ اللهِ وَ الْحَمْدُ لِلَّهِ تَمْلَآنِ – أَوْ تَمْلَأُ – مَا بَيْنَ
السَّمَاوَاتِ وَ الْأَرْضِ ، وَ الصَّلَاةُ نُورٌ ، وَ الصَّدَقَةُ بُرْهَانٌ ، وَ الصَّبْرُ ضِيَاءٌ ، وَ الْقُرْآنُ حُجَّةٌ لَكَ أَوْ عَلَيْكَ ، كُلُّ
النَّاسِ يَغْدُو ، فَبَائِعٌ نَفْسَهُ ، فَمُعْتِقُهَا أَوْ مُوبِقُهَا .

**Нурислам ИБРАҺИМ**

***“Пакълек - иманның яртысы. “Әлхәмдү лилләһ” сүзе үлчәүне тутыра, ә “сүбхәнәллаһи” белән “әлхәмдү лилләһи” сүзләре җир белән күк арасын тутыралар. Намаз - нурдыр, садака - дәлил, сабырлык - яктылык чыганагы, ә Коръән синең файдаңа яки зарарыңа дәлил. Һәрбер кеше иртә белән торып үзен сата, ул шунда үзен коткара, яки һәлак итә”.***

Пакълек - гыйбадәттәге иң мөһим шартларның берсе булып тора. Шуңа күрә мөэмин-мөселман намаз укыганда госелтәһарәтле булырга тиеш. Аллаһы Тәгалә гыйбадәт вакытында шулай ук киемнең дә пакь булырга тиешлеге белән боерган. Бу нәрсәләр мөэмин-мөселманнан никадәр мәшәкать таләп итсә дә, ул үзенең Раббысы каршында чиста, пакь халәттә басып торырга омтыла, чөнки, Аллаһы Тәгалә тәүбә итүчеләрне һәм пакьләнүчеләрне ярата.

Әйе, пакълек - иманның яртысы, чөнки иман китерү зур һәм кечкенә гөнаһларны юса, пакьләнү, ягъни тәһарәт кечкенә гөнаһларны юа, шуның белән ул иманның яртысына тора. Моннан аңлашылганча, иман эчке һәм тышкы пычраклардан арындырса, тәһарәт тышкы пычраклардан арындыра, шулай итеп, ул бу җәһәттән дә иманның яртысына тора.

Пакълек гыйбадәтнең яртысы, дисәк тә була. Чөнки Аллаһы Тәгалә башка бер аятьләрдә гыйбадәтне иман дип атый.

Рәсүлебез үзенең бу хәдисендә зекернең, ягъни Аллаһыны олылау, Аллаһыны мактау сүзләренең никадәр бөек булуын ассызыклап үтә. Һәрвакыт Аллаһыны зекер итү мөэминне күңел тынычлыгына алып килә. Ул кайгылы вакытта да, шатлыклы вакытта да үзен кулда тота белә.

Намаз - нурдыр. Мәгълүм ки, нур ул яктылык. Яктылык исә караңгыда абынмыйча йөрү өчен кирәк. Ул нур мөэмингә туры юлны күрсәтә, яман юлларга кереп китүдән саклап йөри. Чыннан да, намазын ихлас белән укыган мөэмин-мөселман яман, фәхеш эшләрне эшләү түгел, аларга якын да бармый.

Садака бирү иманлы булуга дәлилдер. Әйе, үзең тир түгеп тапкан малны кесәңнән кемгәдер чыгарып бирү җиңел нәрсә түгел. Чөнки нәфес малны бик ярата. Әгәр шул нәфес кешене Аллаһ ризалыгы өчен садака бирүдән тыймый икән, бу аның иманлы булуына дәлил булып тора.

Сабырлык - яктылык чыганагы. Сабырлык югарыда әйтеп үтелгән бөтен нәрсәнең тормышка ашуына алып килүче мөһим бер нәрсә. Сабырлык җиңүгә алып килүче юл. Әгәр мөэмин сабырлыкта дәвам итсә, ул тура юлда булуын дәвам итәчәк. Әгәр сабырлыгы төкәнсә, ул бу мәшәкатьле тормышның хәрабәләре астында калачак. Менә шуның өчен Аллаһы Тәгалә: “Сабыр итүчеләрне сөендер!” - дип Үзенең Коръән Кәримендә безгә хәбәр иткән.

Коръән синең файдаңа, яки синең зарарыңа дәлил.

Ягъни, әгәр Коръән белән гамәл кылган булсаң, ул Ахирәттә синең файдаңа гуаһлык бирәчәк, әгәр юк икән, ул сиңа каршы гуаһ булачак.

Бөтен кеше иртә белән торып үзенең нәфесе белән сатуалуга керешә. Башка нәрсәләргә омтылып яшәгән кеше исә үзенең нәфесенә ияреп эш кылган була. Нәтиҗәдә, ул яки үзен коткара, яки харап итә. Һәркем нәрсәгәдер омтылып яши. Аллаһының гыйбадәтенә, ризалыгына омтылган кеше үзенең нәфесен Аллаһыга сата һәм ул шул сәүдәсе бәрабәренә җәннәткә лаек була.

Дөнья тормышы бик кыска. Шуңа күрә хакыйкый мөселман Бөек Аллаһыга түбәнчелек күрсәтеп, үзенә бирелгән вакыт һәм тормыштан дөнья-ахирәт файдасын хасил кылырга бөтен барлыгы белән омтылып яши.

## Сәламәтлек

### ЗӘЙТҮН МАЕНЫҢ ФАЙДАСЫ



Ул ялкынсынуны баса, авыртуны җиңеләйтә, иң әһәмиятлесе - ул Альцгеймер авыруыннан (баш мие тукымасы бозылып, бөтенләй хәтерсез калу) саклый. Көн саен 1-2 чәй кашыгы май эчү картайгач та аек акылны саклап калу мөмкинлеге бирә. Майдагы олейн кислотасы исә күкрәк яман шешеннән саклый, ә инде шеш барлыкка килгән булса үсүен туктата.

Зәйтүн мае начар холестеринны киметә, гипертония, инсульт, инфаркттан саклый. Иң яхшысы - майны яшелчә салатына сибеп ашау.

### ТИРЕНЕҢ МАТУРЛЫГЫН САКЛАУ

40-50 яшьтән соң тире бик тиз “олыгая” башлый. Моны акрынайту һәм тирене яшь тоту өчен бик җиңел рецептлар бар.

1. Беренче маска болай ясала.

*1 йомырканың агын һәм сарысын аерып аласың. Агын туглап, ярты лимонның согын кушып болгатасың. Кушылманы биткә сөртеп, 5 минут тотасың. Аннан соң җылымса су белән юып аласың.*

2. Икенче маска.

*Йомырканың сарысына 1 чәй кашыгы үсемлек мае, калган ярты лимонның согын салып болгатасың. Бит тиресенә сөртеп, 23 минут тотасың да җылы су белән юып аласың.*

Беренче тапкыр эшләгәндә үк нәтиҗәсен күрерсез.

*“Банан” рецепты бит тиресенең төсен матур тотарга һәм картаюдан сакларга ярдәм итә. Ул да җиңел ясала: ярты бананны чәнечке белән изгәләп, 1 аш кашыгы 10-15%лы сөт өсте, 1 чәй кашыгы бал салып болгатасың. Бит һәм муен тирәсенә ягып, 15-20 минут ятып торасың. Аннан соң җылы су белән юып аласың.*

## Рух куәте

# НАМАЗ ИМАНЫБЫЗНЫ НЫГЫТА

Намазга күнү вә күндерү кечкенә вакытта җиңел булганга күрә, Пәйгамбәребез җиде яшькә җиткән балаларны әкрен генә намазга күндерүне һәм ун яшькә җиткәндә, намазны өйрәтеп, намаз укырга куша. Динебез намаз мәсьәләсендә бик нык торган һәм намазны калдырырга рөхсәт итмәгән. Хәтта, яше бик карт булып, басып намаз укый алмаганнар, утырып укыганнар. Төрле сәбәпләр аркасында вакытында намаз укый алмаганнар каза кылалар.

“Таһа” сүрәсендә Аллаһы Тәгалә: “Әй, Мөхәммәт, гаиләңә вә өммәтеңә намазны куш. Үзең дә намазны дәвам ит…” - дигәннән соң, аятьнең ахырында: “Аллаһтан куркучылар өчен гүзәл (якты) бер киләчәк бардыр”, - дип боерган (132нче аять).

Намаз кальбләрне иман нуры белән яктыртыр. Кешене начар эшләрдән туктатыр, хәерле һәм файдалы эшләргә өндәр, тормышын тәртипкә куяр. Кеше намаз аркылы бик күп гонаһлардан котылып, Аллаһның мәрхәмәтенә һәм изгелегенә ирешер.

Намаз - Аллаһ белән бер илаһи очрашудыр, һәр мөселман өчен чын бәйлелек һәм Аллаһка бирелүдер. Намазда Аллаһның биргән һәм бирәчәк барча нигъмәтләренә шөкер кылабыз һәм Аллаһны олылыйбыз.

Кеше тормышының иң кыйммәтле вакыты - намазда үткән вакытыдыр. Пәйгамбәребез бер хәдисендә: “Кешенең Аллаһка иң якын хәле - намаздагы хәледер”, - дип боерган.

## Өфөлә намаҙ ваҡыты

**Йомадиәл әүүәл-Йомадиәл ахыр 2012 миләди йыл 1433 һижри йыл.**

| Йомаидиәл әүүәл, Йомадиәл ахыр | Аҙна көндәре | Апрель, Май | Иртәнге намаҙ | Ҡояш сығы | Өйлә нам. | Икен. нам. | Аҡшам. | Йәстү намаҙы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 16 | Шәмбе | 7 | 6.04 | 7.34 | 14.30 | 19.33 | 21.03 | 22.33 |
| 17 | Йәкшәмбе | 8 | 6.02 | 7.32 | 14.30 | 19.35 | 21.05 | 22.35 |
| 18 | Дүшәмбе | 9 | 5.59 | 7.29 | 14.30 | 19.36 | 21.06 | 22.36 |
| 19 | Шишәмбе | 10 | 5.57 | 7.27 | 14.30 | 19.38 | 21.08 | 22.38 |
| 20 | Шаршамбы | 11 | 5.54 | 7.24 | 14.30 | 19.40 | 21.10 | 22.40 |
| 21 | Кесе йома | 12 | 5.52 | 7.22 | 14.30 | 19.42 | 21.12 | 22.42 |
| 22 | Йома | 13 | 5.50 | 7.20 | 14.30 | 19.44 | 21.14 | 22.44 |
| 23 | Шәмбе | 14 | 5.47 | 7.17 | 14.30 | 19.46 | 21.16 | 22.46 |
| 24 | Йәкшәмбе | 15 | 5.45 | 7.15 | 14.30 | 19.48 | 21.18 | 22.48 |
| 25 | Дүшәмбе | 16 | 5.42 | 7.12 | 14.30 | 19.50 | 21.20 | 22.50 |
| 26 | Шишәмбе | 17 | 5.40 | 7.10 | 14.30 | 19.52 | 21.22 | 22.52 |
| 27 | Шаршамбы | 18 | 5.38 | 7.08 | 14.30 | 19.54 | 21.24 | 22.54 |
| 28 | Кесе йома | 19 | 5.35 | 7.05 | 14.30 | 19.56 | 21.26 | 22.56 |
| 29 | Йома | 20 | 5.33 | 7.03 | 14.30 | 19.58 | 21.28 | 22.58 |
| 30 | Шәмбе | 21 | 5.31 | 7.01 | 14.30 | 20.00 | 21.30 | 23.00 |
| 1 | Йәкшәмбе | 22 | 5.28 | 6.58 | 14.30 | 20.01 | 21.31 | 23.01 |
| 2 | Дүшәмбе | 23 | 5.26 | 6.56 | 14.30 | 20.03 | 21.33 | 23.03 |
| 3 | Шишәмбе | 24 | 5.24 | 6.54 | 14.30 | 20.05 | 21.35 | 23.05 |
| 4 | Шаршамбы | 25 | 5.22 | 6.52 | 14.30 | 20.07 | 21.37 | 23.07 |
| 5 | Кесе йома | 26 | 5.19 | 6.49 | 14.30 | 20.09 | 21.39 | 23.09 |
| 6 | Йома | 27 | 5.17 | 6.47 | 14.30 | 20.11 | 21.41 | 23.11 |
| 7 | Шәмбе | 28 | 5.15 | 6.45 | 14.30 | 20.13 | 21.43 | 23.13 |
| 8 | Йәкшәмбе | 29 | 5.13 | 6.43 | 14.30 | 20.15 | 21.45 | 23.15 |
| 9 | Дүшәмбе | 30 | 5.11 | 6.41 | 14.30 | 20.17 | 21.47 | 23.17 |
| 10 | Шишәмбе | 1 | 5.08 | 6.38 | 14.30 | 20.19 | 21.49 | 23.19 |
| 11 | Шаршамбы | 2 | 5.06 | 6.36 | 14.30 | 20.21 | 21.51 | 23.21 |
| 12 | Кесе йома | 3 | 5.04 | 6.34 | 14.30 | 20.22 | 21.52 | 23.22 |
| 13 | Йома | 4 | 5.02 | 6.32 | 14.30 | 20.24 | 21.54 | 23.24 |
| 14 | Шәмбе | 5 | 5.00 | 6.30 | 14.30 | 20.26 | 21.56 | 23.26 |
| 15 | Йәкшәмбе | 6 | 4.58 | 6.28 | 14.30 | 20.28 | 21.58 | 23.28 |

## Хикәят

# АГАЧТАГЫ КУНАК



Бер кеше төнне тынычсыз бер кырда үткәрергә мәҗбүр булды. Ерткыч хайваннардан курыкканга күрә, бер зур агачның өстенә менеп утырды. Күп вакыт үтмәде, бер гарип төлке килеп, шул агачның астына сузылып ятты. Агачтагы кунак: “Бу мескен төлке нәрсә ашап, нәрсә эчә икән?” - дип уйлый башлады. Озак та үтмәде ерактан бер арысланның килгәнен күрде. Арысланның авызында бер болан бар иде. Төлке, аны күреп, яшеренде. Арыслан шул агачның астына килеп, табышын ашый башлады. Туйганчы ашаганнан соң, ризыгының бер өлешен калдырып китте.

Арыслан киткәч, төлке, авыр аксап, тагын агачның астына килде вә арысланнан артып калган боланнан ашап, үзен туйдырды. Агачтагы кунак: “Димәк, гарип, хаста бер хайванның да ризыгын Аллаһ аның янына китерә һәм аны ач калдырмый икән. Алай булса, мин нигә көне-төне тырышып, бу кадәр арыймын? Моннан соң мин дә төлке шикелле бер эш эшләмиче, ризыгымны көтеп кенә торыйм”, - диде.

Иртүк юл кырыендагы бер өнгә карап ризыгын көтә башлады. Бер көн, ике көн, өч көн көтте. Ләкин беркемнең дә килгәне һәм ризык китергәне булмады. Ачлыкка чыдый алмыйча, хуштан китеп җиргә төште.

Шул ук вакытта бер төш күрде һәм төшендә бер кеше үзенә шулай диде: “Әй, юләр, әй, ахмак кеше, ялкауланма! Нигә ятып торасың? Тор, тәнең сәламәт чагында эшлә, ялкауланма. Нигә үзеңне гарип төлке урынына куясың? Арыслан шикелле бул да, синең табышыңның артыгыннан башкалар да файдалансын!”

## Кескәйҙәргә уҡығыҙ

# НИҢӘ АЛДАШЫРҒА?

**Фәрзәнә АҠБУЛАТОВА**

Бал ҡорттары бөтәһе лә бер иш тип уйлай күрмәгеҙ. Улар араһында ла төрлөһө бар. Шаяндары, шаяра белмәгәндәре, егәрлеләре һәм ялҡауыраҡтары. Мәҫәлән, Һарыҡас исемле бал ҡорто күберәк уйнарға-көлөргә яратҡан. Ул хатта дуҫтарын шаяртып ҡына түгел, алдап та алыр булған.

Нисек тиһегеҙме? Бал ҡорттары геү килеп бал ташый. Шул мәлдә Һарыҡас бар көсөнә: “Умартаға Айыу килә, Айыу!” - тип ҡысҡырып ебәрә. Бал ҡорттары, бөтөн эштәрен ташлап, үҙҙәренең өйҙәрен һаҡларға тип оса. Айыу юҡ, уның ҡарауы, умарта башында Һарыҡас: “Ә алдағанға ышандығыҙмы, ҡурҡтығыҙмы?” - тип эс тырнап көлөп ултыра.

Ләкин бер мәл, ысынлап та, умарталыҡҡа тайыш табан килә. Һарыҡас: “Айыу!” тип һөрәнләһә лә иптәштәре иғтибар итмәй. Уға ышанмайҙар. Сәскәнән сәскәгә ҡунып бал йыйыуҙарын дауам итәләр. Һарыҡас Айыуҙың моронон сағырға итә, ләкин теге тәпәйе менән берҙе генә һуға. Меҫкенкәй оҙон йөн араһына эләгеп бутала. Шул мәл, ярай әле икенсе бал ҡорто күреп ҡала ла: “Айыу!” тип ҡысҡыра. Ә был ҡортҡа иптәштәре ышана, сөнки ул алдаҡсы булмай.



Тегеләр геүләп килеп етәләр, күмәкләп урман ҡарағын, йәғни Айыуҙы ҡыуып ебәрәләр. Һарыҡасты ҡотҡаралар, тик йыртҡыс менән алышта уның бер ҡанаты зәғифләнә. Шуға ла Һарыҡас хәҙер иптәштәре алып ҡайтҡан бал менән туҡлана. Ул бер ҡасан да алыҫҡа оса алмай.

Бик теләһә лә сәскәләрҙән бал ташый алмай. Алдашырға ла, башҡаларҙан көлөргә лә ярамай шул. Бал ҡорто үҙ ғәйебен бик һуң аңлай.

Адашыу һәр саҡ кешенең үҙенә генә зыян яһай. Дуҫтарҙың ышанысын юғалтыуҙан да насар нәмә бармы икән?